**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 октябрь № 734

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Документларны карап тикшерү һәм объектның, проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында һәм Татарстан Республикасы Президенты Указында билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы мотивлаштырылган бәяләмәләрне килештерү буенча вәкаләтле органнар итеп Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын һәм, аларның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектларны тормышка ашырганда һәм объектларны урнаштырганда, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарын билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Миистрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1034 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 734 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү рөхсәт ителә торган масштаблы инвестицион проектлар туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 ел, 7 декабрь, ПУ-1170 нче Указы (алга таба – Татарстан Республикасы Президенты Указы) нигезендә билгеләнгән критерийларга туры килә торган социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы милкендә, муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү турында юридик затның үтенечнамәсен карап тикшерү процедураларын билгели.

2. Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

объектлар – Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 нче пунктта билгеләнгән таләпләргә туры килә торган социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектлар;

проектлар – критерийлары Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 3 нче пунктта билгеләнгән, критерийларының сыйфат һәм (яки) сан күрсәткечләре Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган масштаблы инвестицион проектлар, шул исәптән сәнәгать (индустриаль) парклары, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары, технопарклар, инжиниринг һәм прототиплаштыру үзәкләре, транспорт-логистика үзәкләре төзү буенча;

үтенечнамә – әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада китерелгән форма буенча, Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә, объектны урнаштыру яки проектны тормышка ашыру өчен, җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү турында юридик зат мөрәҗәгате;

мөрәҗәгатьләрнең җыелма реестры – үтенечнамәләрнең җыелма реестрын алып бару буенча вәкаләтле орган үзе билгеләгән тәртиптә алып баруны тәэмин итә торган кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмаларында юридик

затларның үтенечнамәләре турындагы мәгълүматларны исәпкә алу;

килештерү органнары – тиешле эшчәнлек өлкәсендә объектларның, проектларның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документларны карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, территорияләрендә объектны урнаштыру яки проектны тормышка ашыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары.

3. Сатулар үткәрмичә арендага бирелә торган җир кишәрлегендә проектны гамәлгә ашыру яки объектны урнаштыру максатларында, юридик зат Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы адресына кәгазьдә үтенечнамә җибәрә.

4. Үтенечнамә кертелгән көнне Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан теркәлә һәм үтенечнамәләрнең җыелма реестрына кертелә.

5. Үтенечнамәгә кәгазьдә түбәндәге документлар һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмасында PDF форматында аларның сканлаштырылган күчермәләре теркәлә:

1) үтенечнамәне җибәргән затның вәкаләтләрен дәлилли торган, юридик зат тарафыннан расланган документ күчермәсе (үтенечнамә ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан җибәрелгән очракта, аның төп нөсхәсе бирелә);

2) үтенечнамәгә аңлатма язуы;

3) түбәндәге документларның юридик зат тарафыннан расланган күчермәләре: устав, башка гамәлгә кую документлары, салым органында исәпкә кую турында шаһәдәтнамә, юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдәтнамә, җитәкчене билгеләү турында карар (беркетмә), үтенечнамәне тапшыру көненә кадәр күп дигәндә 30 календарь көн алдан бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

4) узган ике календарь ел һәм агымдагы елның узган хисап чорлары өчен яисә юридик затны төзегән вакыттан башлап узган барлык хисап чорлары өчен (әгәр ул вакыттан соң үтенечнамәне тапшыру көненә кадәр ике календарь елдан азрак вакыт үткән булса) еллык һәм арадагы бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күчермәләре;

5) үтенечнамәне тапшыру көненә кадәр күп дигәндә 60 календарь көн алдан бирелгән, салым түләүче (юридик зат) тарафыннан салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар түләү бурычы үтәлү турында салым органыннан белешмә;

6) юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган, юридик зат белән түбәндәге хәлләр булмау турында белешмә:

юридик затны үзгәртеп оештыру, ябу процедурасын үтүе яки банкротлык хәлендә кулланыла торган процедурада булуы;

юридик затның мөлкәтенә арест салу яки аны тартып алу;

юридик затның хуҗалык эшчәнлеген законнар белән билгеләнгән тәртиптә туктату яки туктатып тору;

Россия Федерациясенә, Татарстан Республикасына һәм (яки) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә акча йөкләмәләре, шул исәптән бюджет

кредитлары буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурычлары булу;

эш хакы буенча бурычлары булу;

юридик затның шартнамәләрдә яки контрактларда күздә тотылган йөкләмәләрен үтәү өлешендә дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алулар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә алып барыла торган намуссыз кайтартучылар (подрядчылар, үтәүчеләр) реестрында, шулай ук «Торак төзелешен үстерүдә булышлык күрсәтү турында» 2008 ел, 24 июль, ФЗ-161 нче Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуссыз төзүчеләр ресстрында булуы;

7) проектны тормышка ашыруның (объектны төзүнең) максатка ярашлы булуын билгели торган, шул исәптән проектны тормышка ашырганда (объектны урнаштырганда) юридик затның керемнәре һәм чыгымнары турында, объектны төзү проектының яки проектны тормышка ашыруның чыгымнары каплану вакыты хакында, аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектларны эксплуатациягә кертүнең планлаштырылган вакытларын күрсәтеп, проектны тормышка ашыруның (объектны урнаштыруның) күздә тотылган вакыты, этаплары турындагы мәгълүматларны, проектның (объектның) финанс моделен, һәркем файдалана алырлык иң яхшы технологияләрне куллану исәпләре хакындагы мәгълүматны үз эченә алган бизнес-план, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын тормышка ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 7 май, 284 нче карары белән расланган форма буенча (масштаблы инвестицион проектны тормышка ашырган очракта);

8) объектны урнаштыруны, проектны тормышка ашыруны финанслау мөмкинлеген раслый торган документлар, шул исәптән объектны урнаштыру, проектны тормышка ашыру кыйммәтенең кимендә 30 проценты күләмендә үз акчаң булуны раслый торган документлар (бизнес-план буенча).

Юридик затның үз акчасы күләме түбәндәге күрсәткечләр буенча раслана:

«Табыш һәм амортизация» – узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы, бу елның чорына – юридик затның бүленмәгән табыш, файдаланылмаган амортизация турында белешмәсе;

«Акцияләрне сатудан (юридик затның счетына күчкән күләмдә) һәм төп фондларны реализацияләүдән акча» – узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы, бу елның чорына – юридик затның әлеге акча булуы турында белешмәсе;

«Юридик зат балансындагы төп акча һәм матди булмаган активлар» – узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы, бу елның чорына – мөлкәтнең калдык кыйммәте турында юридик затның белешмәсе;

9) үтенечнамәдә күрсәтелгән җир кишәрлегенең кадастр паспорты;

10) Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегенә хокуклар турында өземтә яки үтенечнамәне җибәрү көненә кадәр күп дигәндә 30 календарь көн алдан бирелгән, әлеге җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар хакында соратып алына торган

мәгълүматлар Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында булмау турында хәбәрнамә;

11) җир кишәрлегендә урнаштырырга планлаштырыла торган объектның стратегик планлаштыру документларында, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш программаларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килүен раслый торган мәгълүматлар;

12) җир кишәрлеге белән эш итүне гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органыннан җир кишәрлегенең объектны урнаштыру яки проектны тормышка ашыру максатларына һәм бурычларына туры килүен, шулай ук объект урнаштыру яки проектны тормышка ашыру өчен аны бирү мөмкинлеген дәлилли торган мәгълүмат.

6. Әлеге Тәртипнең 5 нче пунктындагы 5 нче, 9 нчы, 10 нчы пунктчаларында күрсәтелгән документлар, шулай ук салым органында исәпкә кую турында шаһәдәтнамә, юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдәтнамә һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә. Эшмәкәрлек субъекты шулай ук Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына алда әйтелгән документларның эшмәкәрлек субъекты мөһере (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) һәм аңа вәкаләтле зат имзасы белән расланган күчермәләрен кертергә хокуклы.

Үтенечнамәгә аңлатма язуы үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

а) җир кишәрлегендә урнаштырырга планлаштырыла торган объектның тасвирламасы, объектның (объектлар урнаштырганда) түбәндәгеләргә туры килүе:

стратегик планлаштыру документларында, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш программаларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга;

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 нче пунктта билгеләнгән объект төренә;

б) проектны тормышка ашыруның максатка ярашлы булуын нигезләп, проектның тасвирламасы, күздә тотылган инвестицияләр күләме, финанслау чыганаклары (проектны тормышка ашырганда);

в) Татарстан Республикасы бюджетына һәм территорияләрендә проектны тормышка ашыру алып барылачак Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына планлаштырыла торган салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр күләме (проектны тормышка ашыру «Татарстан Республикасы территориясендә алына торган салымнардан еллык керемнәрне арттыру» критерие буенча гамәлгә ашырылган очракта);

г) территориясендә проектны тормышка ашыру алып барылачак муниципаль берәмлектә эш урыннары санын арттыруны планлаштыру турында мәгълүматлар (проектны тормышка ашыру «эш урыннарын булдыру яки аларның санын арттыру» критерие буенча гамәлгә ашырылган очракта);

д) объектларны муниципаль милеккә яки Татарстан Республикасы милкенә күчерү турында мәгълүматлар, мондый күчерү планлаштырылса, күчерү вакыты һәм

шартлары;

е) дәлилли торган документларны, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтнамәләр буенча бирелгән документларны теркәп, юридик затның яки аны гамәлгә куючыларның проектларны тормышка ашыру өлкәсендә эш тәҗрибәсе булу яки булмау хакында мәгълүматлар;

ж) юридик затның теркәлүе турында, контрольдә булган чит ил компанияләрен теркәү хакында, салым салуның льготалы салым режимы булган һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләрдә һәм территорияләрдә (оффшор зоналар) файда алучыларны теркәү турында мәгълүмат.

7. Үтенечнамәне һәм аңа теркәлгән, әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы:

үтенечнамәне карап тикшерүне гамәлгә ашыра;

бизнес-планның финанс күрсәткечләрен, проектны тормышка ашырганда критерийларга ирешү мөмкинлеген, шул исәптән салым керемнәрен, эш урыннары санын анализлауны үткәрә;

объектның Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 нче пунктка яки проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган критерийлар күрсәткечләре мәгънәсенә туры килүен яки килмәвен тикшерүне үткәрә;

объектның Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 нче пунктка яки проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган критерийлар күрсәткечләре мәгънәсенә туры килүе турында мотивлаштырылган бәяләмә (алга таба – мотивлаштырылган бәяләмә) әзерли яки үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

объектның Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 нче пунктка яки проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга, Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган критерийлар күрсәткечләре мәгънәсенә туры килмәве;

кертелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар, шул исәптән бизнес-планның финанс күрсәткечләрен анализлау нәтиҗәләре буенча, проектны тормышка ашырганда ирешеләчәк критерийлар күрсәткечләре, әлеге күрсәткечләре ирешү мөмкинлеге хакында дөрес булмаган мәгълүматлар булуын ачыклау;

юридик зат тарафыннан документларны әлеге Тәртипнең 5 нче һәм 6 нчы пунктлары таләпләрен бозып кертү;

җир кишәрлеген үтенечнамәдә күрсәтелгән объектны урнаштыру, проектны тормышка ашыру рөхсәт ителмәгән җирләр категориясенә кертү;

җир кишәрлеген файдалану рөхсәт ителгән , объектны урнаштыру, проектны тормышка ашыру рөхсәт ителмәгән төргә кертү;

җир кишәрлегенең өченче затлар хокуклары белән чикләнгән булуы;

үтенечнамә биргән юридик затка Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирүнең максатка ярашлы булуы турындагы мәсьәләне Инвестицион совет президиумының килештермәве.

9. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, мотивлаштырылган бәяләмәне әзерләгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә әлеге Тәртипнең 5 нче пункты нигезендә юридик зат тарафыннан тапшырылган документлар күчермәләре белән аны, килештерү органнары белән ведомствоара килештерү юлы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул иткән очракта, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, карар кабул ителгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә аныүтенечнамә биргән юридик затка җибәрә.

10. Мотивлаштырылган бәяләмәне карап тикшерү һәм килештерү, мотивлаштырылган бәяләмә килештерүгә килгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә – килештерү органнары, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

11. Мотивлаштырылган бәяләмәне килештерү органнары күрсәткән кимчелекләр белән килештергән очракта, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, килештерү процедурасы тәмамланган көннән соң, үтенечнамә биргән юридик затка, кимчелекләрне эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бетерү өчен, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә килештерү органнарының күрсәтмәләрен җибәрә.

Килештерү органнары күрсәткән кимчелекләрне билгеләнгән вакытта бетергән очракта, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, юридик зат тапшырган документларны теркәп, мотивлаштырылган бәяләмәне билгеләнгән тәртиптә кабат килештерүгә җибәрә. Килештерү органнары күрсәткән кимчелекләрне билгеләнгән вакытта бетермәгән очракта, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы кимчелекләрне бетерү өчен билгеләнгән вакыт чыккан көннән соң өч көн эчендә үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

12. Килештерү органнары, үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул итү өчен әлеге Тәртипнең 8 нче пунктында күздә тотылган нигезләр булса, мотивлаштырылган бәяләмәне килештерми. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мотивлаштырылган бәяләмәне килештермәгән көннән соң өч көн эчендә үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм аны үтенечнамә биргән юридик затка җибәрә.

13. Килештерү органнары мотивлаштырылган бәяләмәне килештергән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 30 көн эчендә кертелгән документларны карап тикшерә һәм Татарстан Республикасы Инвестицион советы президиумына (алга таба –Инвестицион совет президиумы) җибәрә яисә,

үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул итү өчен әлеге Тәртипнең 8 нче пунктында күздә тотылган нигезләр булса, документларны кайтарган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул итү һәм аны үтенечнамә биргән юридик затка җибәрү өчен, документларны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына кире кайтара.

14. Инвестицион совет президиумы үтенечнамә биргән юридик затка Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә, объект урнаштыру яки проектны тормышка ашыру өчен, җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирүнең максатка ярашлы булуы турындагы мәсьәләне килештергән очракта, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә әлеге Тәртипнең 5 нче пункты нигезендә юридик зат тарафыннан кертелгән документлар белән бергә Инвестицион совет президиумы утырышы беркетмәсен, Татарстан Республикасы Президенты боерыгы проектын әзерләү өчен, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрә.

Инвестицион совет президиумы үтенечнамә биргән юридик затка Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә, объект урнаштыру яки проектны тормышка ашыру өчен, җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирүнең максатка ярашлы булуы турындагы мәсьәләне килештермәгән очракта, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм аны үтенечнамә биргән юридик затка җибәрә.

15. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты боерыгы проектын әзерли һәм аны, Инвестицион совет президиумы утырышы беркетмәсен һәм әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы Президенты боерыгы проекты үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

объектның – Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясындагы 2 нче пунктка, проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларның берсенә, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган критерийлар күрсәткечләре мәгънәсенә туры килүе турында мәгълүмат;

юридик затка җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү турында карар;

арендага бирелә торган җир кишәрлегенең урнашкан урыны, кадастр саны һәм мәйданы;

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеген биргән очракта – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тиешле юридик зат белән аренда шартнамәсе төзү йөкләмәсе;

муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген

биргән очракта – җирле үзидарә органына тиешле юридик зат белән аренда шартнамәсе төзү йөкләмәсе.

16. Татарстан Республикасы Президенты боерыгы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карап тикшерү һәм Инвестицион совет президиумы утырышы беркетмәсе белән Татарстан Республикасы Президентына җибәрү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте регламентында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

17. Татарстан Республикасы Президенты боерыгы түбәндәгеләр тарафыннан җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү шартнамәсен төзү өчен нигез булып тора:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан – Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле;

җирле үзидарә органы тарафыннан – муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле.

Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү өчен, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектның, масштаблы инвестицион проектның Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга туры килүен дәлилли торган документ-ларны карап тикшерү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасының
Инвестицион үсеш агентлыгы
җитәкчесе
___________________________
(Ф.И.Ә.и.)

**Җир кишәрлеге бирү турында**
**үтенечнамә**

__________________________________________________________________________,
(юридик зат исеме)

__________________________________________________________________________,
(юридик зат җитәкчесенең, вәкиленең * Ф.И.Ә.и., вазыйфасы)

__________________________________________________________________________,
(Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумироссия классификаторы (ОКВЭД) буенча төп эшчәнлек төре (санын һәм аңлатмасын күрсәтергә)

__________________________________________________________________________,
(теркәлү урыны һәм урнашкан урын адресы (индекс, шәһәр, район))

__________________________________________________________________________,
(телефон, факс, электрон почта адресы)

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кертү турындагы шаһәдәтнамә сериясе һәм саны: ________________________________________________________,

кем тарафыннан һәм кайчан бирелде: ________________________________________,

ОГРН ___________________, ИНН ___________________, КПП _________________.

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясында билгеләнгән критерийларга туры килә торган ________________________________________________
(проект (объект) исеме)
социаль-мәдәни билгеләнештәге объектны, коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектны тормышка ашыру

(тиешлесенең астына сызарга) максатларында, ___________________________________

(җир кишәрлегенең кадастр саны, җир кишәрлегенә хокуклар турында мәгълүмат, урнашкан урыны, категориясе, мәйданы)**

_______________________________________________________________________________

җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирүегезне сорыйм.

_______________________________________________________________________________.

(башка мәгълүмат)***

Кушымта:

_______________________________________________________________________________.

(үтенечнамәгә теркәлгән документлар)

Юридик зат җитәкчесе
(вәкиле) ____________________/______________________

(имзасы) (Ф.И.Ә.и.)

Дата ____________

М.У. (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта)

___________________

* Гаризаны вәкиле тапшырган очракта, ышанычнамә һәм Россия Федерациясе гражданы паспорты күрсәтелергә тиеш.
** Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастрында әлеге җир кишәрлеге турында мәгълүмат булган очракта.
*** Юридик затның ихтыяры буенча гаризада башка мәгълүмат булырга мөмкин.

____________________________________